**Гомеребез озын булсын дисәк.**

Аллаһ Раббыбыз һәрберебезгә гомеребезне билгеләде. Әммә беребездә күпме яшиячәген белми. Йөрәгенең күпме тибеш ясаячагы да беркемгә дә магълүм түгел. Аңар да карамастан мөселман кешесе бу дөньяда да ахирәттә дә бәхеткә илтә торган төп максатын белә һәм таный. “әз-Зәрият” сүрәсенең 56 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә бу хакта болай ди: “Мин кешеләрне һәм җеннәрне миңа гыйбәдәт кылсыннар өчен яраттым”, -диде. Пәйгамбәребезнең хәдис шәрифләреннән билгеле булганча әдәм баласының уртача гомер озынныгы 60 ел тәшкил итә. Сахих җыентыгында урын алган хәдистән болай диелгән: Пәйгамбәребез әйтте: «Минем өммәтемнең гомер озынныгы 60 белән 70 ел арасында булачак. Кешеләрнең бик азлары гына шушы чикне үтә алырлар”.

Шул ук вакытта Раббыбыз”Хадж” сүрәсенең 47 аятендә әйтте ки: “Дөреслектә Раббың каршында бер көн сезнең исәбегездәге мең көн көнгә тиңдер”

Кеше гомерен 60 ел дип алган очракта да Аллаһ каршында бу бары тик бер мизгел генә булып кала.

Шушы 60 елдан 20 елын без йокы хәләтебездә үткәрәбез. Чөнки кешегә көн саен 8 сагәт йокы тиешле. Бу исә кеше гомеренең өчтән берен тәшкил итә. Моны исәпкә алганнан соң безнең 40 елыбыз кала. Магълүм булганча әдәм баласының “тәклиф” яки бәләгат чоры 15 яшькә туры килә. Шушы чорга җиткәннән соң гына кеше үз гамәлләре өчен Аллаһ каршында җавап тота башлый. Димәк безнең 25 елыбыз кала. Моның 5 елын без ашап –ечеп һәм башка иһтияҗларыбызны башкарып үткәрәбез. Ахыры чиктә, барысын исәпкә алганнан соң безнең карамалыгыбызда 20 ел вакытыбыз кала. Сүз дә юк әлеге зекер итеп үткән эшләр-йокы, ашау-эче, күп төрле иһтыяҗларыбызны канәгатләндерү һәм башкалар Аллаһ ризалыгы өчен башкарылсалар шулай ук гыйбәдәткә әвереләләр.  Әммә без сөйләшә торган

калган 20 елыбыз һәрберебез өчен тагын да кадерле. Бу кыска гына вакытны ничек табышлы итеп үткәрергә, аны ничек файдалырак итәргә, сагәтләрнең, секундларның, атналарның һәм айларның хәер бәрәкәтен ничек арттырырга. Гомүмән, гомеребезне озынайтып буламы?

Сүздә юк, тормышыбызны һәм яшәешебезне бәрәкәтле итеп була. Түбәндәге нәсыйхәтләр моңа ирешергә ярдәм итәр.

1) ***Вакытның кадерен белергә өйрәнү.***

   Безнең һәр мизгелебез Аллаһ ризалыгы өчен булырга тиешле. Болай да бик кыска гомеребезне изгелек кылып, гонахлардан тыелып үткәрү көн кебек ачык. Әгәрдә урамда акча яндырып торган кешене күрсәк без аны акылсыз дип әйтер идек. Әммә акчаны эшләп табып була. Кызганыч ки үткән вакытны кире кайтарып булмый.

2) ***Күркәм холыклы булу.***

   Күркәм холыклы булу тормышка бәрәкәт өсти һәм җәннәткә якынайта. Юкка гына түгел пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: “Мин бу дөньяга күркәм холыкны тулыландырыр һәм камилләштерер өчен җибәрелдем”

3) ***Туганнык җепләрен ныгыту.***

   Пәйгамбәребез әйтте: “Туганнык җепләрен ныгыту малны арттыра һәм гомерне озынайта”

4) ***Күршеләр белән яхшы мөгамәләдә булу.***

   Пәйгамбәребез әйтте: “Туганнык җепләрен ныгыту, күркәм холык һәм күршеләргә яхшы мөгамәләдә булу малны арттыра һәм гомерне озынайта”

5) ***Җәмәгат белән намаз уку.***

   Пәйгамбәребез әйтте: “Җәмәгат намазы аерым укыган намазга караганда 27 мәртәбә артыгырак” (Бухари)

Димәк, бер ел буе җәмәгәт намазларын калдырмау 27 елга арттыгырак яшәгәнгә бәрәбәр.

6) ***Өйдә нәфел намазларны торгызу.***

Пәйгамбәребез әйтте: “Кеше күрмәгән җирдә укылган нәфел намазы, кеше күз алдында укылган нәфел намазына караганда 25 мәртәбә артыгырак.” (сахих аль-Җәмигъ)

7) ***Җомга намазында даимчылык кылу.***

Пәйгамбәребез әйтте: «Кем дә кем җомга көнне тәхәрәт алса, үзенең гаиләсен дә җомга намазын укырга үгетләсә, соңыннан җәяүләп мәчеткә юнәлсә һәм имамга якын утырып сөйләшмичә вагаз тыңласа аның һәр адымы өчен ураза белән һәм төнге намазлар белән үткәргәндәй өстәмә бер ел язылыр.» (сахих аль-Җәмигъ)

8) ***Хаҗ гыйбәдәтен үтәү.***

Пәйгамбәребез әйтте: «Харам мәчетендә укылган намаз башка мәчетләрдә укылган намаздан 100000 тапкыр артыгырак, Мәдинә шәһәрендә пәйгамбәребез мәчетендә укылган намаз башка мәчетләрдә укылган намазлардан 1000 мәртәбә артыгырак, «Ал-Акса» мәчетендә укылган намаз 500 мәртәбә артыгырак»

Мәсәлән, әгәрдә сез көненә 12 рикагат нәфел намазы укыйсыз икән елына ул 4320 рикагат тәшкил итәчәк. Әммә Мәккәдә Харам мәчетендә 2 ррикагат намаз укуың 46 ел Аллаһка гамәл гыйбәдәттә булганың дигән сүз.

9) ***Мәчеттә иртәнге намазны укыганнан соң кояш чыкканчы Аллаһыны зекер итеп утыру.***

Пәйгамбәребез әйтте: «Кемдә кем иртәнге намазын мәчеттә укып соңыннан кояш чыкканчы Аллаһыны зекер итсә һәм кояш чыкканнан соң ике рәкагат намаз укыса аңар Хаҗ һәм Гомрә кылу савабы булыр» (ат-Тирмизи)

10) ***Дин дәресләрен алуда даимчылык кылу.***

Пәйгамбәребез әйтте: «Кемдә кем гыйлем өйрәтү яки гыйлем алу максаты белән өеннән чыгып китсә Аллаһы Тәгалә аңа Хаҗ кылу савабын бирер» (Сахих таргиб ва тархиб).

***11) Азан әйтү.***

Пәйгамбәребез әйтте: «Дөреслектә Аллаһ һәм аның фәрештәләре намазның беренче сафларында укучыларга бәрәкәт теләп торалар. Мөәзиннәрне гонахлары азанны сузып әйтү микъдарында кичерелер. Аны ишеткән һәркем аны тәсдыйк кылыр. Мөәззингә аның белән бергә намаз укучыларның әҗер саваплары ирешер”

***12) Ураза тоту.***

Пәйгамбәребез әйтте: “Кем дә кем Рамазан аенда ураза тотып соңыннан шаввал аеның 6 көнендә ураза тотса шул кеше ел буе ураза тоту савабын алыр” (Муслим)

***13) Ураза тотучыны ифтар кылдыру.***

Пәйгамбәребез әйтте: “Ураза тотучыны ифтар кылдыручыга ураза тотучының савабы кимемәгән хәлдә аңар да әлеге әҗер –савап ирешер”.(сахих аль-Җәмигъ)

***14) Кадер кичен гыйбәдәттә үткәрү.***

Аллаһы Тәгалә әйтте: «Кадер киче мең айдан да хәерлерәктер» («ал-Кадер» сүрәсе, 3 нче аять)

***15) Мөселманнарга ярдәм итү, аларның мәшәкатләрен хәл итүдә катнашу.***

Пәйгамбәребез әйтте: «Аллаһ каршында иң сөйкемле кеше – мөселманнарга иң файда китергәнедер. Аллаһ каршында иң сөйкемле эш-мөселманга ирештерелгән шатлыктыр: аның кайгысын уртаклашу, әҗәтен түләргә ярдәм итү, мохтаҗ булса аңа ризык бирү. Мөселман кардәшең белән янәшәдә булу, аңа ярдәм кулы сузу ай буе мәчеттә игътикаф кылудан да хаерлерәктер. Кем үзенең ачуын тыя алды Аллаһ аның кимчелеген яшерер. Кем ачуланырга сәбәпләр булып та сабыр

итеп кала белде, шул кыямәт көнендә күңелендә тынычлык табар. Кем үзенең кардәшенә ярдәм итәргә ашыкты, Аллаһ Тәгалә аның аякларын кыямәт көнендә нык кылыр. Серкә балны бозган кебек, күркәм булмаган холык та гамәлләрне бозадыр.»

**Абдурахман Хәбибуллин**